
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№1
Сентябрь 2018 г.

## С днём знаний!

*Вот и осени дыхание,*
*Новый лист календаря.*
*Снова наступил День знаний —*
*Главный праздник сентября!*

*Ты с хорошим настроением*
*В школу каждый день иди.*
*На любой вопрос решение*
*Сможешь ты тогда найти!*

*И с любой задачей школьной,*
*Знаем, справишься шутя.*
*Радуйся годам веселым,*
*Они быстро пролетят!*



*С уважением, редколлегия газеты!*

## Интересно знать!

- Улитка спит 3 года.
- Самая сильная мышца в теле – язык.
- Тигры имеют полосатую кожу, а не только полосатый мех.
- У морской звезды нет мозга.
- Гигантский кальмар имеет самый большой глаз в мире.
- Кожа белого медведя черная. Его мех не белый, а прозрачный.
- Глаз у страуса больше, чем его мозг.

***Что может быть важнее людей, которые знают так много об этой жизни, обладают мудростью, опытом,***

**Дорогие люди Земли!**
**Сердечно поздравляем Вас с днем пожилых!**

Будьте всегда одарены заботой, уважением, пониманием не только близких, но и окружающих людей. Пусть в душе живет гармония, а в сердце поют соловьи. Пусть будет время и повод для любимых дел, отдыха и наслаждения жизнью. Пусть родные любят и почитают вас!



## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| «Болгар - Туган тел» аланы | 2 |
| “Без - Тукай оныклары!” чатырлы аланы | 3 |
| Феодосиядәге дингез буенда ял иттек... | 4 |
| Җәеңне ничек уздырдың? | 4 |
| “Безопасная железная дорога” | 5 |
| Кросс Татарстана | 5 |

# «Болгар - Туган тел» аланы

***“Сезнең килүегез кояшны да елмаерга мәҗбүр итте. Күләч йөзләрегез белән елмаеп, барлык бәйгеләрдә актив катнашсагыз, һава торышы да сезгә эссе җәйге көннәрен бүләк итәр!”, - шундый матур теләкләр белән ачылыш тантанасы башланып китте.***

Чыннан да, барысы да безнең үзебездән генә тора икән: безне кояш кыздырды, ә без Болгар җирлеген кыздырдык! Әлеге онытылмас мизгелләр белән сезнең белән дә уртаклашасыбыз килә.

«Болгар - Туган тел» аланы - ул татар теле мохитендә яшәү генә түгел, ә тагын тел байлыгын арттыру, аның мөмкинлекләрен ачу да. Быел изге Болгар җирлеге 500 артык иң текә һәм сәләтле яшьләр өчен күңел ачу мәйданчыгы буларак хезмәт итте.

- «Болгар - Туган тел» - ул чын татарлар дөньясы. Биредә татар телен, әдәбиятын яраткан, аның үсеше һәм камилләшүе турында кызыксынган, кайгырган балалар җыелган. Шул балаларга бер-берсе белән аралашырга мөмкинлек бирү – форумыбызның төп максатларының берсе. Шушы ун көн эчендә сәлкешләр кызыклы остазлар, экспертлар белән очрашып, төрле чараларда актив катнаштылар. Бөек Болгарның шифалы һавасыннан, назлы кояшыннан энергия туплап, ел дәвамында аны файдаланып башкаларны да илһамландырырга язсын сезгә! – дип теләде “Сәләт” фондының башкарма директоры Тимур абый Сөләйманов.

«Болгар - Туган тел» аланыны җир шарының барлык сәләтле балаларын үзенә җыйган. Әлбәттә, күбесе Татарстаннан, ләкин араларында башка регионнардан килүчеләр дә шактый. Алар белән дә әңгәмә корырга булдык. Киров өлкәсеннән килгән Әдилә Зыятдинова:

Мин татар әдәбияты олимпиадасыннан беренче урын яуладым. Нәкъ әлеге җинүем мине “Болгар - Туган тел” аланына алып килде дә инде. Мин Әлмәт шәһәрендәге “Дуслык” һәм бүтән ял итү лагерьларында булдым. Монда иң тәҗрибәле укытучылар, шәп атмосфера, кызыклы кичке чаралар уза. Биредә үткәрелүче дәресләр, остаханәләр дә бик үзенчәлекле алып барыла. Киләсе елга да бирегә килермен дип ышанып калам!

“Болгар - Туган тел” аланында катнашырга миңа укытучым тәкъдим итте. Дустымның да әлеге проектта катнашканы бар. Ул миңа бу турыда шул кадәр мавыктыргыч итеп сөйләде, хәтта үземнең дә монда киләсем килде. Интернетта төрле видеолар, фотолар күргәч, кызыксынуым тагын да арта төште. Тиздән мин монда килер өчен гариза да тутырып куйдым, - дип көлә Казаннан килүче Алсу Миргалимова.

Мин әлеге аланнда инде 5 ел рәттән ял итәм. Монда беренче килүемне дә бик яхшы хәтерлим. Ул чакта миңа мәктәптән катнашырга тәкъдим иттеләр. Шуннан соң мин Сәләт дөньясына тулысынча диярлек чумдым: Сәләт-Самара аланында, күпсанлы форумнарда, семинарларда актив катнаша башладым. Әгәр яшь чикләүләре дә булмаса, мин монда әле күп еллар дәверендә килеп күңел ачыр идем, - дип уртаклашты Самарадан килгән сәлкеш Виктория Шамшуидинова.

“Болгар - Туган Тел” форумы инде бишенче ел рәттән уздырыла. Быел аланның беренче юбилее! Ә бу әле башы гына дип ышанып калабыз. Дустым, әгәр синең дә киләсе җәеңне мәңгегә онытылмаслык вакыйгалар белән бизисең килә икән, безгә кушыл!

**Рүзәл ШӘРИПОВ**,
9Б сыйныфы



# “Без - Тукай оныклары!” чатырлы аланы

***Быелгы җәйге ялым «Без - Тукай оныклары» чатырлы аланда күңел ачу белән истә калды. Күп кенә бәйгеләрдә актив катнашып, күп көч түгеп укыганнан соң менә дигән ял булды бу!***

Әлеге алан өченче ел рәттән Арча районы Яңа Кырлай авылында уздырылып килә. Быел да биредә Башкортстаннан, Киров, Оренбург өлкәләреннән, Мари Иленнән, Татарстанның төрле районнарыннан 200 сәләтле бала җыелды.

«Без - Тукай оныклары» аланы - татар теле мохи-тендә яшәү генә түгел, аның мөмкинлекләрен ачу да. Без, татар телен, әдәбиятын яраткан, аның үсеше һәм камилләшүе турында кызыксынган, кайгырткан балалар, үзебезне Тукай оныклары дип горурланып атый алабыз!

Ялыбызны оештыручы-лар безгә бик кызыклы программа әзерләгәннәр. Һәркем үз күңеленә якын булган юнәлештә шөгыльләнә алды. Әйтик, фолкклор, бию, музыка уен коралларында уйнау, рәсем ясау, тубәтәй, калфак чигү. Мондагы тормыш осталык дәресләре белән генә тәмамланмый әле. Кызыклы чаралар, ара-лашулар, күңелле кичәләр, төрле бәйгеләр белән аралашып барды. Язучылар Вакыйф Нуриев, Камил Кәримов, “Салават күпере” газетасыннан Гөлназ Ярмеева, Алисә Дмитриева, татар радиостанци-яләр челтәреннән Айваз Садыров, Рамил Шәрәфиев, “Татар радиосы” алып баручысы Әбри Хәбриев белән очрашу безгә аеруча ошады. Шулай ук без Кушлавыч авылы, Габдулла Тукай музеена экскурси-яләргә бардык.





«Без - Тукай оныклары» аланында гына шәп ат-мосфера, кызыклы кичке чаралар, иң тәҗрибәле укытучылар җыелган. Биредә узучы дәресләр, остаханәләр бик үзенчәлекле һәм кызыклы булды.

- Әгәр дә сез смена дәвамында үзегезне бәхетле хис итәсез икән, бу безнең өчен иң зур бәхет һәм чын ләззәт! Ераклардан агылып килгәнегез өчен рәхмәт сезгә, дуслар! Әйдәгез, рәхәтләнеп ял итик, күңел ачыйк, җырлыйк, биик. Табигать бүләк иткән матур, ямьле җәйнең кадерен белик!

Позитив һәм креатив яшьләр - аланның чын дуслары! Кырлайның шифалы һавасыннан, назлы кояшыннан ел дәвамына җитәрлек көч туплап, аны файдаланып, башкаларны да илһамландырырга язсын сезгә! - диде оештыручылар.

Бу шулай булды да: соры көннәрне кояшың назлы елмаюы алыштырды. Ул безгә көләч йөзе белән елмаеп, безнең күңелләрне күтәрде.

Кыскасы, «Без - Тукай оныклары» аланы бер атна дәвамында татар теле мохитендә яшәтте, тел байлыгын арттырды, дуслаштырды. Иң сәләтле яшьләр өчен күңел ачу мәйданчыгы буларак хезмәт итте. Әгәр киләсе җәеңне дә мәңгегә онытылмаслык вакыйгалар белән бизисең килә икән, безгә кушыл! Киләсе җәйдә очрашканга кадәр!

**Ралинә**
**МӨХӘММӘТГАЛИЕВА,**
4Б сыйныф

*Синең дә үзеңнең иҗат җимешләреңне мәктәп газетасы битләрендә күрәсең киләме? Алайса «Яшь журналист» түгәрәгенә языларга ашык! Ә әлегә үзләрен бу юнәлештә сынаучы беренче карлыгачларыбызның язмаларын сезнең хөкемгә тәкъдим итәбез .*

# Феодосиядәге диңгез буенда ял иттек...

Мин бик зур сабырлык белән көттем каникулны. Ниһаять, килеп җитте ул. Бу җәйдә күңелгә ошаган тәэсирләр күп булды. Башта үзебезнең бакчада бик тырышып эшләдем. Чүгендер, кишер, суган, кыяр чүпләрен утадым. Кич белән телевизор карадым, китап укыдым.

Аннары без ял итәргә Казанга киттек. Көндезләрен, туганнар эштә булганда, балаларын караштык, ә кичләрен Казанның матурлыгын карарга чыктык. Паркларга бардык, Бауман урамында йөрдек.

Бу җәйдә без әле гаиләбез белән Кырымга бардык. Табигатьнең матурлыгына сокландык.

Андагы очсыз-кырыйсыз басуларда сап-сары симәнке һәм карбыз үскәнен күреп сокландык. Виноград басуларын күреп исебез китте. Юлның ике ягында да матур, биек таулар. Феодосиядәге диңгез буенда ял иттек, коендык. Ялта, Севостопль,



Коктебель шәһәрендә экскурсиядә булдык. Миңа Ялтадагы карлыгач оясы дигән замок бик ошады. Минем бу җәем бик күңелле үтте. Хәзер яңа көчләр җыеп укырга тырышабыз.

***Карина ҖАМАЛИЕВА,***

# Җәеңне ничек уздырдың?

***Камилла МИФТАХОВА:***

Табигатьнең иң матур айлары җәй айларына туры килә,һәм безнең иң озын каникул да шул вакытта була. Әй күңелле дә инде җәй көне авылда! Иртән сандугачлар сайравына, этәч кычкыруына уянып китәсең. Урамга чыгасың һәм кояш нурларына чумасын.Ул сине үз кочагына алган кебек була. Ә нинди генә чәчәкләр үсми: зәңгәре дә, сарысы да, кызылы да. Һәркайсы үзенә күрә матур!

Җәй көне авылда эш күп була.Мин әнигә бакчада чүп утарга, җиләк, карлыган җыярга булыштым, бозауларга печән җыеп бирә идем.

Һаман эш кенә эшләмәдек, ял да иттек. Казанга бардык, анда Бауман урамы буенча йөрдек, Кабан күлендә катамаранда йөздек, зоопаркка бардык. Җәйнең актык аенда мин беренче тапкыр "Патриот" дигән лагерга бардым. Без анда хәрби әзерлек үттек, автомат сүтеп җыярга өйрәндек, төрле ярышлар үткәрдек. Ә кич белән дискотекага бардык. Бик күнелле ял иттек. Миңа бу җәйге каникул бик ошады!

***Ислам МИНГАЗОВ:***

Озын уку елыннан соң сагынып көткән каникуллар китеп җитте. Җәйнең беренче көнен озак итеп йоклармын дигән план барып чыкмады.Тиешле вакыт җитүгә күз шардай ачылды. Каникулның беренче көне шулай башланып китте. Җәйге ритмга бик тиз ияләндек. Җылы елга суларында коендык, тәмле җиләкләрен ашадык, зур-зур балыклар да тоттык.

Авылда әби белән бабайга бетмәс эшләрдә булыштык.

Җәйнең иң истәлекле көне - ул минем туган көн.Ул көнне мин тизйөрешле велосипедка ия булдым. Ямьле җәй, шул велосипедта йөргән кебек үтте дә китте. Инде киләсе җәйне көтәбез!

***Ислам Минһаҗев***

Менә инде көтеп алган җәйге каникуллар җитте! Табигатьнең матурлыгына сокланмыйча карап булмый! Нинди матур күк астында яшибез, дуслар! Әзрәк көн үтешләре турында сөйләп китим әле...

Җәйең беренче көннәреннән үк җылы суларда коенырга хыялланган идем, ләкин табигать безгә болытлы, күңелсез көннәр тәкъдим итте. Әмма ай урталарына кояш ямь өләште, һәм без рәхәтләнеп су коендык.

Сез : "Кая су коендың?" – дигән сорау белән бирелгәнсездер. Әби янына авылга кайттым дип җавап кайтарырмын!

Дөресен генә әйткәндә, кире кайтасым да килмәде. Ләкин әни кызыктыра белә, Казанга, "Кырлай" паркына барабыз дигәч, букчаларымны бер мизгелдә тутырдым да, озакламыйча юлга чыктык.

**5Б сыныфы укучылары**

# Лента новостей

С 27 августа по 27 сентября объявлен месячник **“Безопасная железная дорога”** по предупреждению транспортных происшествий с несоверношеннолетними в зоне движения поездов.

В рамках этого мероприятия сотрудники Арского вокзала провели беседы с детжми и напомнили о правилах безопасности вблизи железных дорог.



15 сентября в Арске прошел **“Кросс Татарстана – 2018”,** направленный на популяризацию спортивно-массовых мероприятий в районе, пропаганде здорового образа жизни, вовлечение населения в активные занятия физкультурой и спортом.

В забеге принимали участие, как учащиеся общеобразовательных школ, так и все желающие. Позднее подвелись итоги. Среди победителей и призеров есть и ученики нашей школы.



# Киләсе санда...

**Хәрби әзерлек буенча дәресләрдә син нәрсәләргә өйрәндең?**



- Бу сорауга мин сәгатьләр буе җавап кайтара алам. Иң мөһимнәрен генә әйтеп китим: туган илеңне яратырга, өлкәннәргә, нәни дусларыбызга карата дустанә мөнәсәбәт белән карарга, физик күнегүләрнең иң авырларын да дөрес итеп үтәргә өйрәндем. Хәзер командабыз белән беренче медицина ярдәме күрсәтә, автоматны сүтеп җыя, бердәм команда булып стройда йөри беләбез. Күптәннән бирле автоматтан атарга өйрәнәсе килә иде. Юнармия хәрәкәте миңа шушы хыялымны чынга ашырырга ярдәм итте. Башта куллар да калтырады, мишеньга эләгә алмыйча җафа чигеп, җиргә дә ауткалаган чаклар булды. Ә хәзер исә... кулга автомат кына тоттырсыннар! Баш өстендәге алмага да эләктерә алам! Боларның барысына да без хәрби әзерлек буенча дәресләр үткәрүче укытучыбыз Илдус Аскаров ярдәме белән ирештек…

*(Дәвамы бар)*


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов

***Фотокорреспондент*** Диана Галимова

***Корректор*** Данил Степанов

***Редколлегия*** Алия Хабирова, Гузель Насибуллина

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2